КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 декабрь г.Казань № 1233

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 18 май, 290 нчы карары белән расланган Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 18 май, 290 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 июль, 517 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 1001 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы

бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килгән махсуслаштырылган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин